*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

# ТЫЛСЫМ+

**Икенче сан** **Октябрь, 2014 нче ел**

*Мәгариф идарәләре һәм бүлекләренең милли мәгариф һәм төбәкара хезмәттәшлек буенча методистларының (кураторларының) республика семинар-киңәшмәсенә багышланган махсус чыгарылыш*

## КОЛЛЕКТИВ ТУРЫНДА САНЛЫ АҢЛАТМА

| | |
|---|---|
| РФ гомуми белем бирү мәктәпләренең Почетлы хезмәткәре | 1 |
| «ТР физик тәрбия һәм спорт отличнигы» күкрәк билгесе | 1 |
| ТР ның «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе | 6 |
| РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының Почет грамотасы | 7 |
| ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Почет грамотасы | 8 |
| “Мәгариф” өстенлекле проекты җиңүчеләре | 4 |
| ТР 2010-2015 нче елларга мәгариф стратегиясен тормышка ашыручы “Иң яхшы укытучы” гранты | 16 |
| Югары квалификацион категорияле укытучылар | 19 |
| Беренче квалификацион категорияле укытучылар | 16 |

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ



***Мирзаянов Азат Фәрит улы - Мөслим гимназиясе директоры:***

*XXI гасыр – инновацияләр гасыры. Укучыларның белем дәрәҗәсе заман белән бергә атларга тиеш. «Татарстан Республикасының электрон белем бирү компетенция үзәге» буларак, гимназиядә укыту-тәрбия процессы югары информацион технологияләргә таянып оештырыла. Гимназия коллективы **“Федераль дәүләт стандартларына күчү чорында белем бирү сыйфатын үстерү өчен оптималь шартлар булдыру”** дип аталган методик тема буенча эшли. Киләчәктә Мөслим гимназиясе республикада гомуми белем бирүче инновацион уку йортлары арасында лаеклы үз урынын табар, дип ышанам.*

***Заялова Лира Нурфаяз кызы - Мөслим гимназиясенең укыту эшләре буенча директор урынбасары:***



Уку йортының статусын билгели торган критерий – ул белем сыйфаты. Гимназиядә алган тирән белемнәр укучыларыбызга тормышта үз урыннарын табарга ярдәм итсен иде. “Беләге юан – берне егар, белеме булган – меңне егар” дигән халык мәкале бүгенге көн өчен дә актуаль, минемчә. Фән бәйгеләрендә, фәнни-практик конференцияләрдә, бердәм дәүләт имтиханнарында гимназия укучылары бу хакыйкатьне раслап киләләр. Мөслим гимназиясе укучысы дигән исемне горур йөртегез, тырышып укыгыз. Алдагы уку елы барыбыз өчен дә уңышлар елы булсын!

***Хәбирова Сәвия Закирҗан кызы - Мөслим гимназиясенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары:***



Киләчәк – балалар кулында. Бу уку елында гимназия яңа тәрбия программасы буенча эшли. “Тормыш дәресләре” темасы астында төрле тәрбия чаралары үткәрелә. Аларда районыбызның күренекле шәхесләре, сугыш һәм хезмәт ветераннары, төрле чорларда үзләре пионер, комсомол лидерлары булган активистлар катнаша. Мондый дәресләрнең әһәмияте зур. Программага таянып, укучыларда милләтпәрвәрлек хисләре уятырга, туган җиргә, Ватанга, телебезгә ихтирам тәрбияләргә омтылабыз. Гимназияне тәмамлаган укучылар Мөслимебез елъязмасында матур эшләре белән урын алырлар.

***Мәрданшина Рушания Мөхтәр кызы - Мөслим гимназиясенең методик эшләр буенча директор урынбасары:***



Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан куелган белем сыйфатын күтәрү таләбен тормышка ашыру өчен, укучыларга да, укытучыларга да кулай булырдай яңа алымнар уйлап табарга кирәк. Коллективка компетентлы белгечләр - үз эшенең осталары тупланган. Һәрбер фән иясенең тәҗрибә белән сыналган, үзенә генә хас булган эш алымнары, табышлары, отышлы методикалары бар. Шуларны исәпкә алып, максатчан эш оештырганда, хезмәтебез нәтиҗәле булыр, дип уйлыйм.

## ГИМНАЗИЯ БҮГЕН

**Б**ЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ УЛ – Татарстан Республикасының электрон белем бирү компетенция үзәге.

**Б**ЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ УЛ – Россия “Милли мәгариф” проекты җиңүчесе – 2008.

**Б**ЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ УЛ – “Укучыларның туклануын оештыру буенча иң яхшы мәктәп ашханәсе” VI Республика конкурсы җиңүчесе - 2009.



**Б**ЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ УЛ – медицина кабинетларының Республика смотр-конкурсы җиңүчесе - 2014.

**Б**ЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ УЛ – “Сәламәтлек саклау юнәлешендә “Алтын дәрәҗә”ле мәктәп” квалификацион характеристикасына ия булган уку йорты - 2014.

**Б**ЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ УЛ – 405 укучы, 46 укытучы бердәм эшләүче коллектив.

## ГИМНАЗИЯНЕҢ МИЛЛИ ЙӨЗЕ ФОТОСУРӘТЛӘРДӘ




*Хәсән Туфанның юбилеена багышланган төбәкара конференциядә укытучылар һәм укучылар чыгышы*




*Ата-аналар университетында иҗат концерты*





*Бәйгеләр, очрашу мизгелләре*





## МОГҖИЗАЛЫ ӨЧЛЕК

***“Укытучылык – иң бөек һәм иң изге бер хезмәттер. Дөньядагы барлык байлыклардан да өстен торган гыйлемне өйрәтүче, балаларның да җаннарын тәрбияләүче кеше генә мөгаллим исеменә лаек”.***

***Ризаэддин Фәхретдин***



**Шәнгәрәева Зөлфирә Нәсих кызы** - Мөслим гимназиясенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

### Укучыларыма рәхмәтлемен

Тормыш девизым: Кешеләргә файдалы булып яшәү.

Татар теле укытучысының иң беренче бурычы – балаларда үз теленә карата хөрмәт, җаваплылык тәрбияләү. Дәрескә бирелгән вакыт белән генә чикләнмичә, дәрестән тыш вакытта да алып барылса, бу эш нәтиҗәле була. Бу яктан без, гимназия укытучылары, бик бәхетлеләр. Чөнки гимназиядә татар мохите өстенлек итә. Укучылар, укытучылар ана телендә аралашалар, дәрестән тыш чаралар да татар телендә үткәрелә.

Фәнне яратып үзләштерүче укучылар үзләрен төрле бәйгеләрдә сыныйлар. Укучыларның җиңүләре - укытучының хезмәт нәтиҗәсе ул. Сәләтле балалар белән максатчан эш алып барып, күркәм уңышларга ирешергә мөмкин. Бүген мин республика олимпиадаларында өч ел рәттән җиңү яулаган укучыларым Ләйсәния Җиһангирова, Эльза Гыйздәтова һәм призлы урыннар алган Айгөл Латыйпова, Әлфия Юнысова, Алинә Асманова белән хаклы рәвештә горурланам. Рәсәй һәм республикакүләм иҗади конкурсларда, фәнни-тикшеренү конференцияләрендә Гүзәл Фәхертдинова, Алинә Хәйдәрова, Алсу Шәнгәрәева, Динара Хаҗиева, Айнур Латыйпов, Рузилә Шәяхмәтовалар призлы урыннар белән сөендерделәр. Туган телебезне хөрмәтләгән, аны үстерүдә, танытуда хезмәтләрен куйган укучыларыма рәхмәтле мин.

### Хезмәтем, көчем – милләтем өчен

***“Кешегә бетмәс-төкәнмәс иҗат чыганагы салынган. Менә шул чыганакны ачарга, ireккә чыгарырга, кешегә иҗтимагый тормышта урынын табарга булышырга, аңа үсү өчен тиешле шартлар тудырырга кирәк”.***

***Л.Н.Толстой***



**Тимергалиева Эльмира Васил кызы** - Мөслим гимназиясенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Дезизым: Нәрсәдер эшләргә телисең икән - вакыттан алда бар, нәрсәдер эшләп өлгерергә телисең икән - вакыт белән бергә бар.

Хыялым: Гимназиябезне зыялы татар яшьләре тәрбияләүче белем йорты итеп күрәсем килә.

Хәзерге укучылар турында фикерем: “Булган кешенең кулында бер уч туфрак та алтынга әйләнер,” - ди халык мәкале. Бүгенге буын яшьләр арасында, бәлки, башкалар инде булмас, барып чыкмас, дип уйлаган нәрсәләрне тормышка ашыра алучы шәхесләр үсәдер.

Соңгы елларда укытуда проект технологияләре куллану эш офыкларын киңәйтеп җибәрде. Дәрес кысаларында гына түгел, дәрестән тыш вакытта да төрле кызыклы проектлар өстендә эшлибез. Гимназия газетасы – шундый проектларның берсе. Иҗат белән, журналистика белән кызыксынучы сәләтле балалар бик мавыгып эшлиләр, яңа идеяләр белән янып-көеп йөриләр. Газетаны яшьтәшләре өчен кызыклы, зәвыклы итү теләге белән яшиләр. Дизайн сайлаганда, интервью, репортажлар ясаганда кыю тәкъдимнәр кертәләр. Иҗади төркемдә үз киләчәген шушы юнәлештә күрергә теләүче балалар күп булуы күңелне сөендерә.

Күңеле һәм эше белән гимназиябезнең милли йөзен күрсәтергә тырышучы, туган телебезне, гореф-гадәтләребезне, милләтебезне саклау һәм үстерү, мәдәниятебезне тиешле югарылыкка күтәрү юнәлешендә тырышлык куючы балаларга “Афәрин!” дип әйтәсе килә!



**Авзалова Зилә Зөфәр кызы** - Мөслим гимназиясенең беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

### Әдәбият укытучысы - укучы күңеленә күпер салучы

Һәр халыкның туган теле – аның тарихи көзгесе. Туган җирен чын күңелдән яраткан, халкының тарихына, гореф-гадәтләренә, әдәбиятына, диненә ихтирам белән караган кеше генә туган телен чиксез кадерли. Туган телгә мәхәббәт гаиләдә салына, балалар бакчаларында, мәктәптә дәвам итә. Минемчә, мөгаллим бала күңелендә китап укуга мәхәббәт уята алса, милләт җанлы киләчәк тәрбияләүгә өлешен кертә дигән сүз.

Бүгенге чор укучысы китап укып ләззәт аламы? Бала китап укудан тәм тапсын өчен нишләргә соң? Әлеге сораулар барлык укытучыларны да борчый. Проблеманы хәл итүнең иң ышанычлы юлы – даими рәвештә максатчан эш алып бару. Укучы матур әдәбияттан өлге алырга тиеш. Әдәбият баланың тәрбиясенә, әхлагына, тормышка карашларына йогынты ясый, аны үз-үзенә тәнкыйть белән карарга өйрәтә. Укучының җанын тәрбияләргә дә матур әдәбият өйрәтә. Әдәбият укытучысы, әсәрләр анализлаганда, укучы күңеленә күпер сала, фәнен яраттыра ала. Бер генә фән иясенең дә бала күңеленә юл салу өчен мондый мөмкинлеге юк. Шагыйрь Равил Фәйзуллин: “Китап укып елый алганнарның күңелендә булмый каралык”, - дип яза. Матур әдәбиятка якын бала дөньяның яктылыгын бәяли, гүзәллеккә гамь белән карый, начар эшләргә сәләтле булмый.

# ТАЛАНТЛЫ ЯКТАШЛАРЫМА КҮҢЕЛЕМДӘ ҺӘЙКӘЛ КУЯМ...

***Мөслим төбәге - күренекле шәхесләргә, талантларга бик бай төбәк. Алар иҗаты белән таныш булу – зыялылык билгесе. Яраткан язучыларга "Хыялдагы һәйкәл" проектын тәкъдим итәбез. Теманы өйрәнү барышында без үз асылыбызга кайткандай булдык, киләчәгебез турында матур уйлар туды, күңелләрне шулкадәр талантлар биргән Мөслим төбәге өчен горурлык хисләре биләп алды. Әлеге байлыкны башкаларга да җиткерүне үзебезнең бурычыбыз дип саныйбыз.***

***Проектта 8а, 9б сыйныфы укучылары катнашты.***

***Түбәндәге сораулар тәкъдим ителде:***


***Сез кайсы әдипкә һәйкәл куярга уйлыйсыз?***

***Һәйкәл кайда булырга тиеш?***

***Һәйкәл өчен нинди материал кулай булыр иде?***

***Әдипне нинди кыяфәттә итеп күзаллыйсыз?***

***Һәйкәлгә нинди сүзләр язылган булырга тиеш?***



Татар шигъриятенең "мэтры" саналган **Зөлфәт (Дөлфәт Госман улы Маликов)** Яңа Сәет авылында туган.

Зөлфәтнең заманча актив көрәш рухы белән сугарылган шигъри иҗаты хәзерге татар поэзиясендә үзенчәлекле бер күренеш булып тора. Поэтик фикерне калку, масштаблы итеп күрсәтүгә омтылу, публицистик кайнарлык, трибунлык, халык иҗатына һәм традицион язма әдәбиятына нигезләнгән романтик образлылык, җыйнак композиция, төзек ритмика — Зөлфәт стиленең төп сыйфатлары шулар. Шагыйрь чынбарлык күренешләрен, лирик геройның рухи дөньясын халык язмышы, үткәндәге зур тарихи вакыйгалар яки бүгенге көннең мөһим проблемалары белән фәлсәфи бәйләнештә ачарга омтыла.

Зөлфәтнең һәйкәлен мин Казан паркларының берсендә агачлар арасында – ул яраткан табигать кочагында күрергә телим. Материалына килгәндә, бронза, мәрмәр, граниттан булырга мөмкин. Биек пьедестал өстендә Зөлфәт басып тора. Гәүдәсе, нәрсәдер аңлатырга, халкына олы мәхәббәтен, әйтәсе кыйммәтле сүзләрен җиткерергә теләгәндәй, алга омтылган... Бәдрә чәчләрен азрак җил тузгыткан, киң маңгай, уйчан карашлары өметле киләчәккә төбәлгән. Сул кулында китап, уң кулын факел күтәргәндәй күтәреп, утлы зәңгәр күзләре өстенә җыерчыклар чыгарып, шигырь укый... Нил Юзеевча әйтсәк, шагыйрь – янып яшәү символы. Зөлфәт шау-шулы поэзия күгендә гелт итеп кабынды да үз әдәбияты балкышын гәүдәләндергән якты йолдыз булып балкый. Һәйкәл халкымның татар булып яшәве символы булып күз алдыма килә. Һәйкәлнең аскы өлешенә "Кан туганым, безгә ил хакында сөйләшергә кирәк күзгә-күз" сүзләре язылган.

Зөлфәт һәйкәле янында меңләгән яшьләр. Шулчак мин алар алдында, ялкынланып әдипнең "Буын" шигырен яттан сөйлим.

***Нурислам Сәлимгәрәев***

Прозаиклар арасыннан иң күркәм һәйкәл, әлбәттә, халкыбыз телендә "татарның Шолоховы" исемен йөрткән **Фоат Миңлеәхмәт улы Садриев**ка куелырга тиеш. Һәйкәл өчен урынны да Мөслимнең иң матур ял паркында сайлар идем. Ул иң беренче кояш нурын үзе кабул итеп, таң җилләрен тоя алырлык биек урында торыр, тирә-яктагы тынлыкта киләчәк турында уйланып утырыр кебек. Карашлары ерактагы тауларга төбәлгән... Минемчә, һәйкәлнең материалы бронзадан булырга тиеш. Һәйкәл янында яше-карты ял итеп утырырлык урыннар булдырылырга тиеш. Һәйкәл янына басып, мин аның "Таң җиле" әсәреннән өзекне яттан сөйләр идем. Һәйкәл астында мәрмәр ташка шул ук сүзләрне язып куяр идем.

***Алсу Муллагалиева***



**Шәмсия Гатуф кызы Җиһангирова (Гарипова)** Баек авылында туа.


Шәмсия Җиһангирова - җырчы шагыйрә. Аның шигырьләре табигый агышлы, җырлап тора. Мөгаен, шуңа күрәдер дә композиторларыбыз аның иҗатына аеруча еш мөрәҗәгать итәләр. Укучылар күңелен яулап алган повесть һәм хикәяләр, юмористик әсәрләр авторы да бит әле ул.

Шәмсия Җиһангированың радиодагы эшчәнлеге дә игътибарга лаек. Халык күңеленә юл тапкан, берсеннән-берсе кызыклы «Хәерле иртә», «Гомерләрдән моң һәм сүз кала», шагыйрьләр иҗатына багышланган «Шигырь уты йөрәгемдә», җырның барлыкка килү тарихын ачыклаучы «Остаханә» кебек тапшырулары аның иҗатчы буларак осталыгын, тоткан кыйбласын билгеләүче бер ачык дәлил.

"Исәннәргә һәйкәл кирәк түгел" дисәләр дә, әлеге мәсьәләне хәл итүче булсам, әллә кайчан Шәмсия апага һәйкәл куйган булыр идем. Ир-атларга куелган һәйкәлләр күп, ә хатын-кызларга, ни өчендер, һәйкәлләрне сирәк куялар.

Шәмсия Җиһангирова һәйкәле – хатын-кыз гүзәллеге, фидакарьлеге символы булып торырга тиеш. Мөслим кызлары нинди, дисәләр, мин: "Шәмсия апаныкы кебек чем-кара куе чәчле, тере күзле, тезелеп торган энҗеләрдәй ап-ак тешле, елмайганда, бит очлары чокырлаеп, сине сихерли торган серле, ачык йөзле, туры сүзле, төп-төз гәүдәле," – дип әйтер идем. Скульптор, һәйкәлне ясаганда, һичшиксез, шул таләпләрдән чыгып эш итәргә тиеш. Беркем булдыра алмаганча итеп әнисен яратучы, зурлаучы шәфкать иясе, ихластан туган җирен сагынучы, җирсеп яшәүче милләттәшебез, бер үк вакытта кырыс та, гадел дә, таләпчән дә була белгән зат ул Шәмсия Җиһангирова. Аның һәйкәле янында олы яшьтәге апалар да, гашыйк кыз-кыркын да, егет-җилкенчәкләр дә җыела. Радиодан аның сүзләренә язылган җырлар яңгырый, кемдер кушылып җырлап ала, кайсыдыр шигырь укый. Аллы-гөлле күбәләкләр һәйкәл тирәсендәге хуш исле чәчәкләрне үбәләр, иркәлиләр. Якында гына кошлар сайраганы ишетелә, кечкенә генә куен дәфтәрен чыгарып, бераү күңелендәге хисләрен ак кәгазь битенә төшерә башлый. Матур хисләр уяна, яңа җыр туа, яшь талантлар туа... Минем күңелемә җыр килә...

***Тимур Салахов***



Балалар шагыйре **Мөҗәһит Заһит улы Әхмәтҗанов** Түреш авылында туган.

Мөҗәһит - әдәби иҗатын балаларга багышлаган шагыйрьләрдән. Мөҗәһитнең балалар өчен язган шигырьләре теленең авылчан гадилеге, ихласлыгы белән аерылып тора. Аларда катлаулы сурәтләр, башваткыч вакыйгалар юк, әмма һәр шигырьдә авыл дигән гаҗәеп дөнья өчен генә хас җылылык, нәзакәтлек, кызыклы тормыш детале яки гыйбрәтле бер сабак бар.

Мөҗәһит шигырьләре артында тагын бер кешенең җылы сулышын тоймый мөмкин түгел. Бу сулыш – Укытучы сулышы. Ул күзгә күренеп тормый, әмма аны тоймый калып та булмый. Нәни геройларның, укучы балаларның һәр сүзендә, тәртибендә, табигатькә, яшәешкә мөнәсәбәтендә әнә шул укытучының сүзе, тәртибе, мөнәсәбәте дә чагыла төсле. Шулкадәр матур, самими һәм табигый бәгланышны, берләкне бары тик чын шагыйрь, чын укытучы да булган кеше генә күрсәтеп бирә ала.

Мөҗәһит Әхмәтҗанов гарәп хәрефләрен өйрәнүчеләр өчен "Күңел нуры", "Гарәп графикасы нигезендә элекке татар язуы" исемле уку әсбаблары, туган авылы Түреш турында тарихи очерк һәм Мөслим төбәгеннән чыккан каләм ияләре турында биографик белешмә, Мөслим районындагы фольклор ансамбльләре турында "Мөслимем җәүһәрләре", Мөслим авылындагы мәчетләр, мәдрәсә, мәктәпләр тарихына багышланган "Кыңгыраулы мәктәп еллары" исемле һ.б. китаплар авторы буларак та укучыларга билгеле. Бүгенге көндә яшь курайчылар түгәрәге алып бара. Иҗат итәргә, нәфис сүзгә теләге булган балалар белән өстәмә рәвештә шөгыльләнә. Мөҗәһит Әхмәт-җанов – халык мәгарифе отличнигы, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы, 1995 нче елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Мин Мөҗәһит Әхмәтҗанов һәйкәлен үзе күп еллар җитәкләгән мәктәп каршында итеп күз алдына китерәм. Биредә шигырь укучылар конкурслары, төрле әдәби чаралар үткәрергә булыр иде. Ә Мөҗәһит абый, сөенеп, шул чараларны күзәтеп торыр иде. Аның янында халык уен кораллары ансамбльләре чыгыш ясар, табышмак кичәләре шаулап үтәр.

***Язилә Исмәгыйлева***

## УКУЧЫЛАРЫБЫЗНЫҢ ФӘННИ-ТИКШЕРЕНҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

# Беренче төбәкара “Фоат Садриев укулары”





Татар теле һәм әдәбияты укытучылары инициативасы белән, 2014 нче елда районыбызда беренче мәртәбә “Фоат Садриев укулары” оештырылды.

Гимназия базасында уздырылган фәнни-тикшеренү эшләре конференциясендә Минзәлә, Актаныш, Азнакай, Мөслим районы һәм Яр Чаллы мәктәпләреннән укучылар һәм укытучылар катнашты. Якташыбыз данлыклы



прозаик, драматург Фоат Миңлеәхмәт улы Садриев – Габдулла Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе, халык язучысы. Үз туган җиренә хыянәт итмичә, башкаланың уңайлы яшәү шартларына, иҗат өчен уңайлыкларына төкереп, карьера үсеше өчен кызыклы тәкъдимнәрне кире кагып, Мөслимебездә яшәп иҗат итеп ятучы фидакарь зат ул!

Ул яктырткан темалар - халыкның йөрәге аша үткән темалар, шуңа күрә әсәрләрендәге халыкчан образлар һәрберсе укучы өчен якын, үз. Мин “Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” поэмасы һәм Фоат Садриевның “Таң җиле” романында аваздаш мотивлар” темасы буенча тикшеренү эше башкардым. Без 9 нчы сыйныфта татар мәктәпләре укыту программасы буенча Болгар чорының күренекле ядкәре булган әсәр - Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” поэмасы белән таныштык. Поэма мине үзенә җәлеп итте. Болгар чоры шагыйренең “Йосыф” сүрәсендәге таныш эчтәлекне сюжетның нигезе итеп алуы юкка түгелдер. Фоат Садриевның “Таң җиле” романын укыгыннан соң, бу ике әсәрдәге аваздашлыкны күреп гаҗәпкә калдым. Укытучыбыз белән берлектә бу әсәрләрне чагыштырып анализларга, кешелекнең яшәешендәге төп әхлакый кыйммәтләрне барларга, борынгы Болгар чоры



әдәбиятыннан ук килгән мотивларны ачыкларга алындык. Эшебез шактый катлаулы, шул ук вакытта мавыктыргыч булып чыкты.

Автор, бернинди мораль укымыйча гына, үзләренә дә сиздермичә, тылсымчы кебек оста алымнар белән, кешеләр күңеленә әхлак кануннарын яза алган. Башка бер генә профессия иясе өчен дә мондый мөмкинлек юк. Фоат Садриевның бөеклеге дә шул гадилектәдер, минемчә. Гомумән алганда, роман - мәгънәле яшәеш, мәгънәле үлем турындагы әсәр. Ике әсәрне тикшерү миңа тормыш кануннары турында нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирде. Фоат Садриевның “Таң җиле” романы - һәр йортта өстәл китабы булырга лаеклы әсәр.

***Чын укытучы укучысына мең еллар хезмәт көче куелган әзер бинаны күрсәтми, ә төзелеш материалын эшкәртүгә юнәлеш бирә, аның белән бергә бинаны төзи һәм төзергә өйрәтә.***

***Адольф Дистервег***



Фоат Садриевның иҗаты турында бик күп фикерләр әйтелсә дә, нигездә, аңа тиешенчә бәя бирелмәгән әле, дип саныйм. Укучыларның фәнни-тикшеренүләре алдагы елларда да олпат язучыбызга игътибарыбыз, ихтирамыбыз билгесе буларак, дәвам итсен иде. Мондый эшнең гамәли кыйммәте зур.

***Зәринә Габдуллина,***
***11нче в сыйныфы укучысы***

# МӨСЛИМ РАЙОНЫ АВЫЛЛАРЫ ТАРИХЫ: ҮТКӘНЕ, БҮГЕНГЕСЕ, КИЛӘЧӘГЕ

## Кече Ватаным – данлы Түрешем

*Урман түрләреннән агып чыккан*
*Шуңа исем тапмый тор имеш!..*
*Тормыш үзе исем кушкан аңа*
*Гади генә итеп: Түр Инеш.*
*Харрас Әюп*

Бабам Мөслим авылының кечкенә дә төш кенә булган Түреш авылында туган. Бу авылга узган гасырның егерменче еллар башында нигез салына. Кара урман уртасына Кубәк авылының дистәләгән таза ир-атлары Түреш дигән авылга нигез салалар. (Түреш – "түр инеш" сүзләреннән ясалган, кубәклеләр аны шулай йөрткәннәр). Авылга күченүчеләр арасында бабамның бабасы Әбүталип та булган. Бабам сөйләвенчә, күченеп килүчеләр, шул чор таләпләре буенча, җир сорап, Мәскәүгә хат язганнар, ләкин кайбер гаиләләр, җавапны көтеп тормыйча, күченә дә башлаганнар. Кубәк авыл советы рәисе Шәйхеталип абыйга Мәскәүдән хат килеп төшә. Урысча белмәгәнлектән, хатны уку өчен Түрешкә күчеп өлгергән Гәрәйхан Морзаханов янына китә. Хатта, урманнарны саклау максатыннан, Түреш авылына нигез салырга рөхсәт бирелмәве турында язылган була. Гәрәйхан, хатны укып чыга да: "Сиңа-миңа кирәк әйбер юк монда," – дип, хатны янып торган калай мичкә ыргыта. Шулай итеп, Түреш авылы яшәп китә.

Авыл тарихы ил тарихы белән бик тирән бәйле. Утызынчы еллар башында колхоз төзелә. Бөек Ватан сугышы елларында авылда бары тик хезмәткә яраклы унлап ир-ат һәм алтмышка якын хатын-кыз исәпләнә. Сугыш чорында колхоз белән хатын-кызлар идарә итә. Кечкенә генә авылдан яу кырында утызга якын Түрешле ятып кала. Егерменче гасырның алтмышынчы еллар уртасында бабамның авылында җитмешләп йорт исәпләнә. Түреш авылы халкы бик укымышлы һәм тырыш була, анда һәр йорт капкасына бер югары белемле кеше туры килгән. Бабамның әйтүенчә, моның сәбәбе авылга күченеп килүчеләрнең хезмәт сөючән булуында һәм башлангыч мәктәп укытучыларының белемгә омтылыш тәрбияләвендә.

Авыл үзе зур булмаса да, тарихи шәхесләргә бик бай. Аннан бөек Ватан сугышының башыннан ахырына кадәр юл үткән, сугышчан орденнар белән бүләкләнгән, тыныч хезмәттәге казанышлары өчен Ленин ордены алган Исмәгыйль Әюпов, партиянең XXII съезды делегаты, колхоз рәисе Мирза Гаттаров, Татарстанның атказанган механизаторы Лерон Гыйльфанов һ.б., күренекле шагыйрьләр, танылган артистлар, бик яхшы җитәкчеләр чыккан.

Минем бабам Низамов Илгиз Хафиз улы сугыштан соң колхозчы гаиләсендә туа. Шул чорга хас булган язмыш аны да читләтеп үтми: ачлы-туклы тормыш, кечкенә генә салкын өй, шул өйдә бер үк вакытта сарык бәрәннәре, бозаулар үсәләр... Авыл урман эчендә урнашуга карамастан, мичкә ягарга утыннары булмаган, чөнки урманга керү катгый тыелган. Авылда башлангыч мәктәпне тәмамлагач, бабам биш чакрым ераклыктагы Кубәк урта мәктәбенә йөреп укый. Язгы-көзге көннәрдә, кышкы бураннарда юлсызлык аның күңеленә гомерлеккә уелып калган. Шулай булса да, ул мәктәп елларын аеруча җылы итеп искә ала.

Бабам белән бергәләп, аның фотолар альбомын карарга яратам. Каралы-аклы фотоларда күпме истәлек! Менә монда 12-13 яшьләрдәге пионер галстугы таккан малайлар. Бөтенесе бер төсле форма кигәннәр, прическалары да сәер сыман... Бабам үз өлешләренә тигән пионерлы балачагын, комсомоллы яшьлек елларын исенә төшерә. Үзем дә сизмәстән, мине дә шул чор рухы биләп ала. Бозаулар өчен күмер, тавык фермасына көл җыю, макулатура, тимер-томыр җыю өмәләре безнең буын өчен бөтенләй ят нәрсәләр. Шулай булса да, бу эшләр ул чор өчен бик әһәмиятле эш булган, балаларны уртак максатлар берләштергән, алар хезмәт чыныгуы алган.

Мәктәпне тәмамлагач, бабам Казан дәүләт педагогия институтына укырга керә. Спорт, җәмәгать эшләрендә актив катнаша. Башкалада укыган студент еллары фотоларында бабам - бөтен кызларны гашыйк итәрлек егет! Зәңгәр күзле, куе бөдрә чәчле булдыклы егет үзе кебек укымышлы, тәрбияле, чибәр кызны - әбием Роза Нәгыймовнаны яр итә. Институтны тәмамлаганнан соң, ул үзе укып чыккан Кубәк мәктәбендә тарих фәне укыта. Яшь белгечнең оештыру сәләтен, җәмәгать эшләрендә башлап йөрүен күреп, яшьләр оешмасы белән җитәкчелек итәргә район комсомол комитетының беренче секретаре итеп сайлап куялар. Бу чорда район комсомол оешмасы күп тапкырлар комсомолның өлкә һәм Үзәк комитетларының байракларына лаек була. Бабамның үзенә комсомол Үзәк комитеты бүләкләре тапшырыла. Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 30 еллыгы уңаеннан Мәскәүдә СССР оборона министрлыгы музеенда Җиңү байрагы янында бер төркем генераллар белән фотога төшү бәхетенә ирешә.

Сиксәненче-туксанынчы елларда ул Мөслим үзидарә башлыгы булып эшли. Бу чорда бабам Мөслим авылының социаль үсеше өчен күп көч куя, республикада беренчеләрдән булып, район үзәген тулысынча газлаштыру проектын тормышка ашыруда үзеннән зур өлеш кертә. Ике меңенче елдан ул коммуналь хуҗалык оешмасын җитәкләде, лаеклы ялга чыкканчы шунда хезмәт куйды. Бу чорда коммуналь хуҗалык объектлары энергия саклау алымнарына күчерелә, бу хезмәтләре өчен ул хөкүмәт бүләкләре ала. Кайда гына эшләмәсен, авылдашлары аның хезмәтеннән канәгать, урамда очратсалар да, туктап, аңа рәхмәт әйтеп китәләр. Аның белән Мөслим урамнарында рәхмәт сүзләре ишетеп йөрү миңа да рәхәт, күңелемне бабам өчен горурлык хисләре биләп ала.

...Альбомның бу битен актарганда, бабамның битен күз яшьләре чылатканын күргәнем бар. Монда аның сабакташы, иң якын дусты, фикердәше, авылдашы Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе шагыйрь Харрас Әюпов рәсемнәре. Бабам аның шигырь китапларын да бик еш кулына ала. Харрас абый төрле елларда үзенең 12 китабын, истәлекле сүзләр язып, бабама бүләк иткән. Түреш, аның тырыш халкы, онытылмас балачак еллары, саф сулы чишмәләр, газиз әнкәйләр, туган тел турында ул шигырьләр. Харрас абыйны да шагыйрь иткән, үстергән авыл бит ул Түреш!

Кызганыч, Харрас абый бик иртә дөнья куйды. Бабам аның белән бәйле истәлекләрне бик кадерләп саклый. Харрас абый кул сәгатьләре җыя торган булган. Берсен бабама да бүләк иткән. Мин бик кызыксам да, бабам аны бирми: "Анда Харрас абыеның җаны саклана, - ди.

Бабамның тагын бер гаҗәеп авылдашы Татарстанның халык һәм Россиянең атказанган артисты Наил Әюповның да фотолары саклана бу альбомда. Мин әле кечкенә идем. Бабам мине үзе белән авылга алып кайтты, Наил абый белән таныштырды. Без бергәләп урманга, су буйларына бардык. Наил абый бара торган җирдән машинаны туктатырга кушты. Күз




яшьләре аралаш, һәр агачны сөеп, сыйпап йөрде. Үтә дә нечкә күңелле авылдашыбыз Наил Әюповның туган җирен сагынып җирсүе дә, Түреш белән саубуллашуы да булган икән бит ул!.. Наил абыйның Түрешкә соңгы кайтуы булды бу. К.Тинчуринның "Зәңгәр шәл" драмасында Булат образы аша тамашачының мәхәббәтен яулаган артист, гаҗәеп моңлы тавышлы, бик күп башка җырлы рольләрне зур осталык белән башкарган Татар Академия театрының мәшһүр актеры Н.Әюпов бакыйлыкка күчте. Аның турында минем күңелемдә бары тик якты истәлекләр саклана. Ильтани Иляловaның "Наил Әюпов. Иҗат портретына штрихлар" дигән китабында бабамның да актер белән төшкән фотосы бар.

Фотоальбомның алдагы битендә кураен тотып елмаеп басып торучы бу абыйның күп төрле уен коралларында уйнап безне шаккаттыручы Татарстанның атказанган укытучысы, Абдулла Алиш исемендәге премия лауреаты, Язучылар берлеге әгъзасы балалар шагыйре Мөҗәһит Әхмәтҗанов икәнен мин таныйм. Ул да бабамның авылдашы – Түреш егете. Мөҗәһит абыйның үз кулы белән язып бүләк иткән китапларын мин бик кадерләп йөртәм, безнең кебек шук малайларга адресланган шигырьләрен кат-кат укыйм. Авылда Мөҗәһит абыйның умарталыгы бар. Җәй житкәч, яңа аертылган бал белән сыйлый ул безне.

Ә бу фотода безнең "Күрше абый". Үз исеме белән әйтмибез, ни сәбәпледер, "Күрше абый" дип кенә йөртәбез без аны. Гомере буе таң белән бергә тракторын кабызып кырга чыгып киткән, кояш баткач кына өенә кайткан Лерон абый. Җир сөргән, иген үстергән, хезмәтеннән ямь табып яшәгән. Лерон Гыйльфанов – Татарстанның атказанган механизаторы. Бүгенге көндә дә бик актив, энергияле карт үзе. Лерон абыйның улы шагыйрь Ләбиб Лерон да Түрештә туган.

Мин бабам һәм аның авылдашлары белән горурланып үсәм. Алар ил кичергән барлык авырлыкларны да үз җилкәләрендә күтәргәннәр. Авылым язмышы ил язмышы белән тыгыз бәйләнгән. Түреш егетләре ил язмышын үзләренеке иткәннәр, илгә, халыкка хезмәт итеп дан казанганнар. Аларның шундый күренекле булуларында Түрешнең матур табигате, күркәм холыклы, мәрхәмәтле авылдашларының да өлеше зур, әлбәттә. Бабамның миңа да, энем Булатка да шул тәрбияне бирергә тырышканын мин бик яхшы аңлап торам. Тормышта үз урынымны табармын дип уйлыйм, Түрешләләр турында сөйләгәндә минем исемемне дә матур яктан телгә алуларын телим.

***Камил Микалин,***
***11 нче в сыйныфы укучысы.***

*Фотода - язмада исемнәре телгә алынган шактый шәхесләр. Икенче рәттә сулдан беренче утырганы – минем бабам Низамов Илгиз Хафиз улы.*

## УКУЧЫЛАР ҺӘМ УКЫТУЧЫЛАР ИҖАТЫНА БАГЫШЛАНГАН СӘХИФӘ



# Таң җиледәй әкрен генә назлап,
# Бүген җанны шигырь уятты.

### Матурлыкка карыйм сокланып

Сызылып кына таңнар аткан чакта,
Сәер генә, бераз уйланып,
Сөенеп туялмыйча, исем китеп,
Матурлыкка карыйм сокланып.

Матурлыкка карап сокланам мин,
Бәхетләләр парлап узганда.
Сөенечем ташый, бәреп тышка,
Сөйгән ярым янда булганда.

Матурлыкка карап сокланам мин,
Дус-ишләрем тугры булганда.
Гади чәчәкләрдән илһам эзлим,
Күңелләрем нурга тулганда.

Матурлыкка карап сокланам мин,
Якыннарым бердәм булганда.
Дөрес киңәшләрен юлдаш итәр
Әткәм-әнкәм исән булганда.

Матурлыкка карап сокланам мин,
Җемелдәшеп бакса йолдызлар.
Ачык йөзле кешеләргә карыйм –
Бу матурлык тагын тагын кайда бар?
Матурлыкка карап сокланам мин...

***Гөлназ Мирзасалихова,***
***башлангыч класслар укытучысы***

### Әнием елмаюы

Синдәй матур елмаючы
Бу дөньяда бар микән?
Нигә әни елмаюы
Шулкадәр якын икән?

Күктә - кояш, Җирдә – әни
Елмаеп җылытучы.
Сөеп, назлап, кадерләп
Иркәләп уятучы.

### Көзге этюд

Баш очымнан гына тезелеп
Кучмә кошлар очып бара.
Көзге кояш сагышланып,
Моңсу гына озатып кала.

Кошлар киткәч агачлар да
Сагыштан саргаялар.
Яшь түгә болытлар да,
Көннәр кыска, төннәр озаялар.

Әле генә кояш иде,
Чиләкләп койды бая.
Көзге көнне аңламассың:
Я елый, я елмая…

***Әһлиуллина Язилә,***
***9 нчы б сыйныфы укучысы***

### Ашыгам

Чәчкән кебек җиргә орлыкларны
Белем гөлен сибәсем бар,
Сабыйларның күңеленә
Өмет, шатлык бирәсем бар.

Аннан кояштай иркәләп,
Үскәнен күрәсем бар,
Ык суында чыныктырып,
Зур тормышка илтәсем бар.

Киләчәккә маяк өчен
Ышаныч бирәсем бар.
Бу тормышта сыгылмаслык
Канатлар куясым бар.
Ашыгам, вакытым тар...

***Эльмира Тимергалиева,***
***татар теле һәм әдәбияты***
***укытучысы***

### Армиягә китәсең...

Озакламый безне, абыем,
Озын юл аерачак.
Син кайтуга инде бездә
Күп яңалык булачак.

Син, абыем, бер ел буе
Илебез чиген сакларсың.
Әбиемнең син кайткачтын
Беләм рәхәт суласын.

Ныклы булып, тугрылыклы
Хезмәт ит Туган илгә.
Өмет итәм: син кайтырсың -
Нур булып туган өйгә.

***Рәмилә Сәләмова,***
***7 нче б сыйныфы укучысы***

## Бүләк

*(Хикәя)*

Кышкы кич. Фирүзә өстәл янында уйга чумып утыра.

Кызым, нинди уйга баттың? Чәең суынып бетә ич.

Әнием, абыемның туган көненә кәчек бүләк итсәм, ничегерәк булыр икән?

Бик шәп булыр, кызым.

Тиз арада гына каян табарбыз соң аны, кызым?- диде әтисе.

Күптән түгел генә Фирүзәләрнең Пушок атлы этләре картаеп дөнья куйды. Абыйсы бу югалтуны авыр кичерде, чөнки абыйсы белән Пушок бик дуслар иде. Пушок Камилне койрыкларын болгый-болгый, шатланып каршы ала иде. Камил, кая гына барса да, этне үзеннән калдырмады. Шуңа күрә дә, кәчек бүләк итеп, Фирүзә абыйсының күңелен күтәрмәкче иде. Озак эзләде кыз кәчекне. Абыйсының туган көне килеп җитте, ә кәчек юк.

Фирүзә һәр кичтә әтисенә маллар караша. Юеш борынлы бозауларның кетер-кетер печән ашаганнарын күзәтеп торырга, учын сузып, тәмле печән белән сыйларга ярата. Шулай бер кичне, малларны карап, эшләрен тәгәлләгәч, Фирүзә бакча ягына чыкты. Ак-ак кар шәлләрен бөркәнеп утырган агачларга сокланып карап торганда, әллә каян кара йомгак тәгәрәп чыкты. Кыз куркып китте. Аның аяк астында түм-түгәрәк, кара күзле, йомшак, йонлач, кара кәчек бөтерелә иде. Ул туктаусыз шыңшый, аякка сарыла, җылы эзли кебек тоелды. Фирүзә як-ягына каранды, хуҗасын эзләгәндәй итте. Тик берәү дә күренмәде. Күрәсең, кәчек хуҗасыз иде. Кызның шатлыгы эченә сыймады. Кәчекне кулына алып, күкрәгенә кысты. Кәчек "Менә ич минем хуҗам", дигәндәй, сөенеп, кызның битләрен, кулларын ялады.

Фирүзә абыйсын зур түземсезлек белән көтте. Тизрәк абыйсына шатлыклы хәбәр җиткерәсе, кәчекне бүләк итәсе килде.

Шулай итеп, Бүләк ишек алды хуҗасы булып, Фирүзәләрдә яшәп калды.

***Илүзә Кашапова,***
***8 нче а сыйныфы укучысы***

## КӨН ЯҢАЛЫКЛАРЫ

### «Интеллект» клубы

Гимназия директоры А.Ф. Мирзаянов инициативасы белән, бу уку елында сәләтле балалар белән шөгыльләнүче «Интеллект» клубы эшли башлады. Укучылар белән гимназиянең иң яхшы укытучылары, республиканың югары уку йортларыннан чакырылган галимнәр дәресләр үткәрәчәк, уен-тренинглар уздыру планлаштырыла. Клубны оештыруның төп максаты: төрле дәрәҗәдәге интеллектуаль чараларда нәтиҗәле эшчәнлеккә ирешү.



Идеяне тормышка ашыру өчен, клубның гомуми җыелышында оешманың структур бүленеше кабул ителде. «Интеллект» клубы җитәкчесе - тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы И.Н. Юлдашев. Гуманитар һәм табигать фәннәре юнәлешендәге бүлек белән рус теле һәм әдәбияты укытучысы Ч.А. Хәйруллина һәм биология укытучысы Л.Ф. Бариева, ә информацион бүлек белән Э.В. Тимергалиева шөгыльләнә. Шулай ук укучылар арасыннан клубның Президенты, кызыксыну-мавыгулары буенча аерым төркемнәр булдырылды.

«Интеллект» клубы киләчәктә гимназиянең прогрессив үсешен тәэмин итәрлек проект булыр, дип саныйбыз.

***Илдар Юлдашев, тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы***

### Чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез белән элемтәләр эзлибез

2010 ел җан исәбе буенча, Русиядә татарлар 5 310 649 кешене тәшкил итә, чит илләрдә исә татарлар саны 1,5 миллионнан 3 миллионга кадәр.Татар халкының байтак өлеше якын чит илләрдә яши. Үзбәкстанда татарлар күп - 656 601 кеше, Казахстанда 331 151, Украинада 133 596 милләттәшебез көн күрә.



Татарлар Төркиядә, Румыниядә, Польшада, Кытайда, АКШта, Финляндиядә, Австралиядә, Япониядә, кайбер гарәп илләрендә, хәтта Латин Америкасында да яшиләр. Чит илләрдәге татарлар, үз телләрен һәм мәдәниятләрен саклап, аерым җәмгыятьләр булып гомер итәләр. Алар төрле илләрдәге татар җәмгыятьләре, Татарстандагы милләттәшләре белән тыгыз элемтәдә торалар. Гимназия чит илләрдәге милләттәшләребез белән элемтәләр булдыру өстендә эшли.

Хезмәттәшлек итәргә теләүче милләттәшләребез өчен электрон адресыбыз: tilsim.gimnazia@yandex.ru.

***Азилә Кадыйрова, информатика укытучысы***

## Котлыйбыз!




*Гимназиянең директоры А.Ф.Мирзаянов җитәкчелегендә районыбызның яшь укытучылары Самара өлкәсендә “Яшь педагогларның методик идеяләр фестивале”ндә катнашып, җиңүләр белән кайттылар. Уңышлар чылбыры дәвамлы булсын, яңа үрләр яулавыгызны телибез, хөрмәтле укытучыларыбыз!*

***Мөслим гимназиясе укучылар үзидарәсе***

### *Укучы мөнбәре* (сораштыру нәтиҗәләре)

***Гимназия укучысының тышкы кыяфәте турында бәхәсле фикерләр яшәп килә. Укучылар нинди формадан йөрергә телиләр? Бүгенге сораштыру шул турыда.***

***Эльвина:*** *Миңа үзебез кия торган форма бик ошый. Ап-ак алъяпкычлардан пөхтә итеп киенеп өйдән чыгып киткәндә, кунакка килгән әбием сокланып карап кала, күз яшьләрен сөртеп, үзенең яшьлеген хәтеренә төшерә. Минемчә, модалы киемнәрнең үз урыны була. Дәресләргә барлык укучы бердәм кабул ителгән формадан йөрсә, уку да нәтиҗәлерәк була кебек.*

***Алсу:*** *Мин дә форма кию ягында, чөнки көн саен иртән нинди кием кияргә дип баш ватасы юк.*

***Булат:*** *Кызларның матур киенәсе килә, әлбәттә. Аларга кара күлмәк белән канатлы ак алъяпкычлар бик килешә!*

***Язилә:*** *Заманча мода белән тегелгән яңа төр формалар кертелсә дә начар булмас иде.*

ТЫЛСЫМ+
Октябрь, 2014 нче ел
***Мөслим гимназиясе укучылары газетасы***

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Исмәгыйлева Язилә
**Корректорлар:** Ханеева Камилә, Солтанова Эльвина
**Корреспондентлар:** Муллагалиева Алсу, Кашапова Илүзә
**Дизайнер:** Галиев Илназ

**Компьютерда җыючылар:** Гилемов Азат, Ибраһимов Ильяс
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym